Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 475-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 24 сентябре
№ 2476-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 759. «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (475-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (475-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 24 сентябре
№ 2477-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 760. «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 477-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 477-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 24 сентябре
№ 2478-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 761. «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (477-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (477-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 24 сентябре
№ 2479-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 762. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 473-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Т.Г. Һадиев һәм Р.Р. Гайзатуллин тарафыннан кертелгән «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 473-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2018 елның 24 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте



комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2018 елның 24 ноябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 24 сентябре
№ 2480-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 763. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составындагы үзгәреш турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Хәсәнов Рөстәм Ринат улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составына кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетын сайлау турында» 2014 елның 1 октябрендәге 17-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының икенче абзацына (2015 елның 20 февралендәге 455-V ДС, 2016 елның 3 ноябрендәге 1432-V ДС, 2016 елның 28 ноябрендәге 1509-V ДС, 2018 елның 20 февралендәге 2177-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән), «12» санын «13» санына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 24 сентябре
№ 2481-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**764. «Әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тартудан гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ростов өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тартудан гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ростов өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Ростов өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 24 сентябре
№ 2482-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**765. «Россия Федерациясе Салым кодексының 123 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 527676-7 номерлы федераль закон проекты хакында (салым агентын җаваплылыктан азат итү өлешендә)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Салым кодексының 123 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 527676-7 номерлы федераль закон проектын (салым агентын җаваплылыктан азат итү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 24 сентябре
№ 2483-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**766. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 391 һәм 407 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 544565-7 номерлы федераль закон проекты хакында (2018 елның 31 декабренә гамәлдә булган Россия Федерациясе законнары нигезендә пенсия билгеләү өчен кирәкле шартларга туры килә торган физик затлар өчен мөлкәт салымнары буенча федераль ташламаларны саклап калу өлешендә)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 391 һәм 407 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 544565-7 номерлы федераль закон проектын (2018 елның 31 декабренә гамәлдә булган Россия Федерациясе законнары нигезендә пенсия билгеләү өчен кирәкле шартларга туры килә торган физик затлар өчен мөлкәт салымнары буенча федераль ташламаларны саклап калу өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 24 сентябре
№ 2484-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 767. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 546281-7 номерлы федераль закон проекты хакында (салым ташламаларын һәм салымнан азат итүләрне тикшереп тору, исәптә тоту һәм бәяләү процедураларын бюджет процессы кысаларында системалаштыру һәм регламентлаштыру өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 546281-7 номерлы федераль закон проектын (салым ташламаларын һәм салымнан азат итүләрне тикшереп тору, исәптә тоту һәм бәяләү процедураларын бюджет процессы кысаларында системалаштыру һәм регламентлаштыру өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 24 сентябре
№ 2485-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 768. «Федераль дәүләт янгын күзәтчелеге эшчәнлеген камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 518816-7 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Федераль дәүләт янгын күзәтчелеге эшчәнлеген камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 518816-7 номерлы федераль закон проектын хупларга.



2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 24 сентябре
№ 2486-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 769. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышын 2018 елның 24 сентябрендә 10 сәгатьтә Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концертлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 17 сентябре
№ 2420-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 770. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәлә турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышы каравына «Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Сове-

тына республиканың эчке һәм тышкы хәле турында еллык юлламасы хакында»гы мәсьәләне кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 17 сентябре
№ 2421-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 771. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышын телевидение һәм радио аша турыдан-туры трансляцияләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2018 елның 24 сентябрендәге кырыгынчы утырышын телевидение һәм радио аша турыдан-туры трансляцияләүне оештырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 17 сентябре
№ 2422-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 772. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык беренче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык беренче утырышын 2018 елның 24 сентябрендә



12 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 17 сентябре
№ 2424-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 773. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык беренче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык беренче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары вазыйфаларын башкару турында.
3. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларын раслау турында.
4. Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзаларын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләрен сайлау турында.
5. «2019 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында» 486-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 481-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Пенсиягә федераль социаль өстәмә күләмен билгеләү өчен Татарстан Республикасында 2019 елга пенсионерның яшәү

минимумы күләмен билгеләү турында» 490-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 482-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 472-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «2019 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 484-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. «2019 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 483-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 487-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 8 пунктының үз көчен югалтуын тану турында» 488-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» 442-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 453-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

16. «Югары Ослан муниципаль районының «Вахитов авыл җирлеге» һәм «Шыланғы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм



аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 474-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 492-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

18. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 478-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 16 һәм 33 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 485-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

20. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 480-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

21. «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 479-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

22. «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 471-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

23. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 476-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

24. «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 475-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

25. «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 477-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

26. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 473-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

27. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составы үзгәрү турында.

28. «Әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тартудан гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ростов өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

29. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында кинематографияне үстерү турында».

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 17 сентябре
№ 2425-V ДС

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘЛӘРЕ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 774. Л.В. Малыгинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан региональ хезмәттәшлеккә һәм үсешкә ярдәм итү фонды директоры идарәчесе Малыгина Людмила Владимировнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 3 сентябре
№ 463-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 775. С.В. Соколованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Бердәм Россия» гомумроссия сәяси партиясе Татарстан төбәк бүлекчәсенең Алабуга җирле бүлеге җирле башкарма комитеты җитәкчесе Соколова Светлана Вильевнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 3 сентябре
№ 464-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 776. Г.Х. Ильясованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Эшләр идарәсенең чараларга хезмәт күрсәтү һәм биналарны карап тоту бүлекчәсе өлкән белгече Ильясова Гөлсәйдә Хатыйп кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 3 сентябре
№ 465-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 777. Ф.Ф. Мифтаховны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының Казан бүлеге җитәкчесе Мифтахов Фәрит Фәиз улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 3 сентябре
№ 466-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 778. Э.Ә. Хәсәнованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мәдәният идарәсе башлыгы урынбасары Хәсәнова Эльмира Әгъдәс кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 3 сентябре
№ 467-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 779. Р.Х. Солтангированы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыяте филиалы «Маяк» газетасы редакциясе» бүлек мөхәррире Солтангирова Резида Хәбиб кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 3 сентябре
№ 468-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 780. Р.М. Фәтхуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен Болак буендагы яшьләр театры баш режиссеры, Татарстан Республикасы Халык сәнгате кәсепләре һәм һөнәрләре палатасы әгъзасы Фәтхуллин Рөстәм Мулланур улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 3 сентябре
№ 469-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 781. Э.Р. Вәлиуллинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Югары Судының бүлек башлыгы – баш бухгалтеры Вәлиуллина Эльмира Разыйх кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 3 сентябре
№ 470-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 782. Е.В. Шакированы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты өлкән мөгаллиме – читтән торып уку факультеты методисты Шакирова Елена Валериевнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 3 сентябре
№ 471-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 783. И.Ф. Ягъфаровны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Лениногорск агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры Ягъфәров Ирек Фидарис улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 3 сентябре
№ 472-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 784. Г.Т. Сафинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Эдем» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры Сафина Гөлнур Таһир кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 4 сентябре
№ 473-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 785. Р.Х. Шакировны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Маркс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте трактористы Шакиров Рәис Харис улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 4 сентябре
№ 474-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 786. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 478-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (максатчан кабул итү турында нигезләмәләрне төшереп калдыру өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 478-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын 2018 елның 4 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 5 сентябре
№ 475-РК

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 787. Ф.Р. Кәримовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында җирле үзидарәне үстерүгә зур өлеш керткән өчен Азнакай муниципаль районының «Кәримова Нәсимә Салих кызы» крестьян-фермер хуҗалыгы башлыгы Кәримов Фәнүс Рәис улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 5 сентябре
№ 476-РК

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 788. Г.Р. Садыйкованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Балтач район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең ветеринария табиб-токсикологы Садыйкова Гөлшат Равил кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 6 сентябре
№ 477-РК



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 789. Н.Б. Хәкимовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Әгерҗе район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең ветеринар табибы Хәкимов Наил Барый улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 6 сентябре
№ 478-РК

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 790. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 480-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (шәһәр җирлегенең һәм шәһәр округының җирле әһәмияттәге мәсьәләләре исемлеген киңәйтү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 480-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын 2018 елның 5 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 5 сентябре
№ 479-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**791. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Ш.Ш. Яһудин һәм Р.Г. Ногманов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 479-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләренең аерым вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә) алдан карау турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 479-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты күрсәтелгән закон проектын



2018 елның 4 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 7 сентябре
№ 480-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**792. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары И.Н. Бакова, Т.В. Воропаева, Р.Ш. Ганибаев, Г.Н. Глушков, С.М. Захарова, Ю.З. Камалтынов, Е.И. Кузьмичева, Т.П. Ларионова, Л.Н. Маврина, Р.А. Ратникова, Л.Н. Шәфигуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 481-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (2019 елның 1 гыйнварыннан пенсия алды яшендәге затларга социаль ярдәм чараларын саклап калу өлешендә) алдан карау турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 481-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Күрсәтелгән закон проектын Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясындагы 3 өлеше нигезендә бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты күрсәтелгән закон проектын 2018 елның

5 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 7 сентябре
№ 481-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 793. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүгә турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 482-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (иминият суммаларының һәм иминият премияләренең билгеләнгән күләмнәрен үзгәртү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүгә турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 482-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын 2018 елның 8 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 10 сентябре
№ 482-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 794. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 16 һәм 33 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 485-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (муниципаль берәмлек исеменнән оешмалар белән идарә итүдә муниципаль хезмәткәрләрнең катнашу тәртибен төгәлләштерү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 16 һәм 33 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 485-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын 2018 елның 8 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 10 сентябре
№ 483-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 795. М.Р. Мотыйгуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Лаеш районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Мотыйгуллин Марсель Риян улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 10 сентябре
№ 485-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 796. Н.П. Кузьминаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен Казан дәүләт мәдәният институты музыка сәнгате факультетының этнография сәнгате һәм белеме кафедрасы профессоры, «Татарстан Республикасының рус милли-мәдәни берләшмәсе» региональ иҗтимагый оешмасы әгъзасы Кузьмина Нина Петровнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 11 сентябре
№ 486-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 797. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «2019 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 483-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «2019 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 483-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына, аны закон проекты буенча өстәмә башкаручы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасына һәм юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты күрсәтелгән закон проектын 2018 елның 7 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 11 сентябре
№ 487-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**798. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «2019 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 484-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «2019 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 484-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына, аны закон проекты буенча өстәмә башкаручы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасына һәм юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты күрсәтелгән закон проектын 2018 елның 7 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 11 сентябре
№ 488-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**799. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «2019 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында» 486-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

